Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 16 октябре № 2/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 05 июнендәге 70/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 июнендәге 70/1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 пунктына, 1 һәм 2 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:
«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем яки урта һөнәри белем булу – Җирлек вазыйфаларының барлык төркемнәре өчен;
2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:
муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;
муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы А.В. Сашин